**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№10489**
**12.12.2025**

Хәрби хәрәкәтләр ветераннарына
һәйкәленең дизайн-проектлары
конкурсын үткәрү турында

Яр Чаллы шәһәренең «Махсус хәрби операциясе ветераннарының шәһәр Советы» Ассоциясе рәисе Ш.Н. Әюпов, Әфганстандагы сугыш һәм башка локаль конфликтлар инвалидларының Татарстан Республикасы иҗтимагый оешмасының Яр Чаллы территориаль бүлеге рәисе Э.Н Фоминыхның хәрби хәрәкәтләр ветераннарына һәйкәл кую мәсьәләсе буенча мөрәҗәгатен карап тикшергәннән соң, Россия Федерациясенең «Ватанны саклаганда һәлак булганнар истәлеген мәңгеләштерү турнида» 1993 елның 14 гыйнварындагы 4292-1 номерлы Законы, шәһәр Уставының 41 статьясы нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Хәрби хәрәкәтләр ветераннарына һәйкәленең дизайн-проектлары конкурсын үткәрергә.
2. Хәрби хәрәкәтләр ветераннарына һәйкәленең дизайн-проектлары конкурсын оештыру комитеты составын, 1 нче кушымтада каралганча, расларга.
3. Хәрби хәрәкәтләр ветераннарына һәйкәленең дизайн-проектлары конкурсы оештыру турында нигезләмәне, 2 нче кушымтада каралганча, расларга
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары И.Ә. Сәлимхановка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2025 елның 12 декабрендәге
10489 номерлы карарына
2 нче кушымта

Хәрби хәрәкәтләр ветераннарына һәйкәленең
дизайн-проектлары конкурсын үткәрү турында нигезләмә

1 бүлек. Гомуми нигезләмәләр

1. Хәрби хәрәкәтләр ветераннарына һәйкәленең иң яхшы проектына ачык конкурс, Ватанны яки аның мәнфәгатьләрен саклаганда һәлак булганнарны хәтердә саклау максатыннан ( алга таба - Конкурс) үткәрелә.
2. Конкурс бер этапта үткәрелә.
3. Конкурсның максаты булып ярыш нигезендә иң яхшы архитектур-сәнгати эшне ачыклау һәм хәрби хәрәкәтләр ветераннарына багышланган һәйкәл проектының авторын (авторларын) билгеләү тора.
4. Проектларны бәяләү критериеләре: идеянең үзенчәлеге, уникальлелек, һәйкәлнең тәэсирлелеге, проектлана торган объектның югары дизайнерлык, эксплуатация күрсәткечләре белән характерланган, һәйкәлнең архитектура-сәнгати матурлыгы.
5. Конкурсның оештыручысы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлегенең Башкарма комитеты тора.
6 Конкурс үткәрү турында мәгълүмат Конкурс оештыручысының рәсми сайтларында һәм социаль челтәрләрендә урнаштырыла.

2. Конкурсның максаты

7. Конкурс ярышы шартларында хәрби хәрәкәтләр ветераннарына һәйкәл проектының монумент, скульптура-декоратив конструкция рәвешендәге, архитектура-сәнгати матурлыгы, автор яңалыгы белән аерылып торган, ясалуы буенча тиз һәм экономияле, транспортлау һәм урнаштыру буенча техгнологик яктан гади булган иң яхшы эскизны ачыклау.

3. Катнашу шартлары

8. Конкурста дизайн-концепцияләр эшләү буенча эшчәнлек алып баручы оешмалар; «Дизайн»укыту программасын тормышка ашыручы югары һәм урта һөнәри уку йортлары коллективлары һәм студентлары катнаша ала.
9. Конкурсны оештыручы түбәндәге функцияләрне башкара:
1) Конкурсны әзерләү һәм үткәрүне тәэмин итү;
2) катнашучыларның гаризаларын һәм эшләрен кабул итү;
3) жюрины формалаштыру;
4) конкурсны мәгълүмати тәэмин итү;

4. Конкурсны уздыру тәртибе һәм шартлары

10. Конкурста катнашу өчен заявкалар тапшыру чоры 2025 елның 1 декабреннән 2025 елның 31 декабренә кадәр.
11. Катнашучылар түбәндәге документлардан торган конкурс пакетын тапшыралар:
1) фамилиясе, исеме, атасының исеме, компаниясе, вазыйфасы, почта адресы, телефоны һәм электрон почтасы күрсәтелгән заявка;

2) һәйкәл проекты (3D);

3) һәйкәлнең зурлыкларын күрсәтә торган проекцияләр;

4) һәйкәлнең тасвирламасы белән аңлатма язуы (һәйкәлнең үлчәмнәре, булачак һәйкәлнең нинди материалдан ясалуы, проект авторының ниятен җентекләбрәк ачарга мөмкинлек бирә торган башка материаллар күрсәтелә)

Һәйкәл проекты JPEG форматында 1920x1080 кечерәк булмаган зурлыкта тәкъдим ителә. Сәүдә маркалары сурәтләре яки авторлык хокуклары белән саклана торган элементлар булган эшләр кабул ителми.

12. Конкурска гаризалар Конкурста катнашучылар тарафыннан «Һәйкәлләр конкурсы» тамгасы белән түбәндәге электрон почтага җибәрелә: kancel.chelny@tatar.ru.

13. Автор яисә авторлык коллективы проектны Конкурска җибәрү факты Конкурсны уздыруның әлеге Нигезләмәдә билгеләнгән шартлары белән Килешүне аңлата.

14. Материалларны тапшыру вкыты һәм форматы үтәлмәгән заявкалар Конкурста катнашуга кертелми.

15. Конкурста катнашучы конкурс заявкасын әзерләүгә һәм Конкурста катнашуга бәйле барлык чыгымнарны үз өстенә ала.

16. Конкурста катнашу өчен бер генә гариза бирелгән яисә бер гариза да бирелмәгән очракта, Конкурс үткәрелмәгән дип таныла.

## 5. Бәяләү критерияләре

17. Конкурска тапшырылган эшләр, составы әлеге карар белән расланган Оештыру комитеты тарафынаннан түбәндәге критерийлар буенча бәяләнә:

1) конкурсның максатлары һәм бурычларына туры килүе;

2) башкару сыйфаты;

3) кабул итү эстетиклыгы;

4) оригинальлеге;

5) проектны тормышка ашыру мөмкинлеге (дәүләт программасы буенча проектның финанс чынбарлыгы);

6) архитектура-сәнгати кыйммәтләре;

7) композициянең идея-сәнгати әһәмияте.

18. Конкурсны оештыру комитеты, Конкурста катнашучыларга хәбәр итеп, Конкурсны үткәрү срокларына үзгәрешләр кертү хокукын үзендә калдыра.

## 6. Җиңүчеләрне билгеләү

19. Конкурс эшләрен карап тикшерү һәм Конкурска йомгак ясау буенча жюри утырышы 2026 елның 12 гыйнварыннан 2026 елның 31 гыйнварына кадәрге чорда уздырыла;

Конкурс нәтиҗәләрен игълан итү - 2026 елның 31 мартында.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева